МУНИЦИПАЛЬ АВТОНОМИЯЛЕ МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАСЫ ”ТӘРБИЯ ҮЗӘГЕ–
92 САНЛЫ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ “ЛАДУШКИ”

№6

# "Ладушки"



*Дөньяда*
*иң - иң*
*матур тел*
*Ул -*
*минем*
*туган телем.*



**26 апрель 1886 ел - 2 апрель 1913 ел**

## *Туган тел*

И туган тел, и матур тел,
әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән
әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм
хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта
ярдәмең белән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
шатлыгым, кайгым
минем.

И туган тел! Синдә булган
иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
әткәм-әнкәмне, ходам!

1909 ел

Тукай турында күренекле кешеләр:

***Тукай мирасы яшәгәндә, милләтебез дә яшәр, татар халкы милләт булып яшәгәндә Тукай да яшәр. (М.Шәймиев)***

***Тукайның бәхете шунда ки, ул үзенең бөтен үсуен, күтәрелуен халкыбызның үсуе, күтәрелүе белән бергә баглап алып барган. (Гаяз Исхакый)***

**Тукай гасырлар шагыйре. (Фәрваз Миңнуллин)**

***Тукай –величина духовная, нравственная, художественная, просто неизмеримая (Игорь Ряхин)***

Туры Тукай

Ул ятим дә, ул мескен дә диеп
Сөйләнелгән элек- электән.
Күз алдына аны боек итеп
Китерергә күпләр күнеккән.

Әйтерсең лә Тукай бар гомерен
Арка туңып кына яшәгән.
Ләхәүләсен укытып
Ишмиләрнең
Яшен булып шагыйрь
яшьнәгән.

Әйткән сүзе – аткан угы һәрчак
Туры тигән, читкә китмәгән.
Зирәк халык аны юкка гына
“Туры Тукаебыз” димәгән!

Мескен халык, мескен хаклык
булмый,
Мескен шагыйрь була дисеңме
Батыр дигән сүзгә рәттән
куйыйк
Тукай дигән горур исемне.

Якты йолдыз булып атылган ул
Зәгыйфь чәчәк булып сулмаган.
Туры Тукай, моңлы Тукай
булган,
Бөек булган, боек булмаган.

Ш.Галиев

**Тукай эзләре буйлап**




***Тукай биографиясе — дөнья әдәбияты тарихындагы иң драматик биографияләрнең берсе. Шагыйрь узган юл озын түгел. Аның төп урыннары Кушлавыч — Кырлай — Өчиле — Казан—Уральск, яңадан Казан...***

***Ләкин шул авыллар, шул шәһәрләр арасында күпме фаҗига***




!






**Мөхәммәтгариф улы Габдулла Тукаев элекке Казан губернасы Мәңгәр волосте Кушлавыч авылында мулла семьясында туа. Габдулла биш айлык чакта әтисе үлә. Шуннан кулдан-кулга, авылдан-авылга.  Ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, кимсетелүләр..**



Әтисе Мөхәммәтгариф



Әнисе Мәмдүдә

**Казанда Тукай музее**





















*Поэта жизнь, короткая такая,*
*Была смертельный бой,*
*великий труд.*
*Недаром день рождения Тукая*
*В Казани днем поэзии зовут.*
**Марк Зарецкий**





***ГАБДУЛЛА ТУКАЙ*** *прожил короткую и трагическую жизнь. Родился он 26 апреля 1886 года в деревне Кушлавуч Казанской губернии (ныне Арского района) в селе приходского муллы Мухамедгарифа.*

*Рано лишившись родителей, он скитался по чужим углам в деревнях Училе (1890г) Сасна, Кырлай ( 1892-1894)*



**Всё о Габдулле Тукае:**

1894 – 1907 годы
Габдулла Тукай живёт в Уральске, в семье тёти Газизы Забировой (Усмановой)

Революция 1905 года всколыхнула жизнь в Уральске. Здесь появились первые татарские газеты и журналы: «Фикер» («Мысль»), «Уклар» («Стрелы»). Тукай публикует свои уже не подражательные, а оригинальные стихи.


Новые веяния, предвещавшие подъём революционного движения, оказывали на него заметное влияние в условиях медресе. При активном непосредственном участии Тукая выпускается рукописный журнал «Эль-гаср- эль-джадид» («Новый век»), в котором он публикует свои первые ученические стихи и статьи. Он переводит басни И.Крылова и предлагает их к изданию

1895 – 1898 годы
Одновременно с медресе Тукай обучался в трёхлетней русской школе.


Тукай вошел в историю татарской литературы как великий поэт, заложивший основу новой национальной поэзии, как один из основоположников современного татарского языка. Творческая деятельность поэта продолжалась всего восемь лет. Он умер в возрасте 27 лет

# *Әкиятләрдә халык язмышы*



















# Төннәр буе әнкәй ярдәмендә Тукай шигырьләрен ятладым

**Күбәләк:**
Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын
Якты көн булганда.

Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;
Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.

Тик гомрем бик кыска:
Бары бер көн генә,—
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа

Безнең гаилә

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби,
бабай һәм бер песи —

Безнең өйдә без җидәү:
безнең, песи — җиденчесе.

Сөй гомерне, сөй халыкны,
сөй халыкның дөньясын,

Без үләрбез, билгеле, тик
үкенечкә калмасын.

Бишек җыр
Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, угълым, йом күзен,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сина теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!

Кошларга

Курыкмагыз, кошлар, күреп сез
янгызда мин барын;
Мин тимәм сезгә, фәкать
сайравыгызны тыңларым.

Җырлагыз сез күңлегезгә тәңре
нәрсә салганын;
Мылтыгым да юк янымда, юк
шулай ук ауларым.

Бик тынычлап сайрагыз сез, мин
тимим, сезгә тимим;
Әллә иркендә торуның кадрене
белмимме мин?!

Курыкмагыз— яхшы беләм, мин
һич тә сезне ауламам;
Сайрагыз, тыңлап торырмын, тын
да алмам, шауламам.

Туган авыл
Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям жаным-тәнем белән.

Ходай шунда жан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Корьән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәтне,
Ничек михнәт, жәфа күргән, ничек торган.

Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп, кара жирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер — кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган жирем.










**_Без Тукайлы халык мәңгегә_**

















***Бөек Тукайның 129 еллыгына багышланган чыгарылышны I кечкенәләр төркеме коллективы әзерләде.***

***Тәрбияче Латипова Ләйсән Газиз кызы***

